# Ислам нуры

اسلام نورى

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 24 (676) 21 декабрь 2018 ел (1440, Рабигул-ахир) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Гыйлем учагы



Кукмара якларында гомер итүче халыкның тырыш, уңган, хезмәт сөючән дигән даны еракларга таралган. Үзләрендә җитештерелгән киез итекләре, савыт-сабалары, кием-салымнары турында әйтәсе дә юк... Әлеге районны үз күзебез белән күреп кайткач, бар сорауларның сер ачкычы булган гади генә бер хакыйкатькә төшенеп өлгердек: баксаң, бик күпләрнең гамәле иман нуры белән өртелгән, ислам кануннарына нигезләнеп көйләнгән ләбаса! Кайдадыр икенче берәүләр тормыштан зарланудан башканы белмәсә, биредә яшәүчеләр җир җимертеп эшләргә дә, дини гыйлем алырга да, мәчетләр төзергә дә, авылы-авылы белән намазга басарга да теләген-вакытын таба.

Кукмарага юл тотуыбызның төп сәбәбе - андагы данлыклы мәдрәсәнең 20 еллык юбилей кичәсенә чакырулары иде. 1998 елдан бирле эшләп килгән мәдрәсә бүген үзенең шәкертләре, мөгаллимнәре белән дә, эшчәнлеге белән дә хаклы горурлана ала. Укуны тәмамлаганнарның күбесе инде үзләре халыкка аң-белем бирү белән мәшгуль. Мәчетләрдә имамлык итүчеләр дә - мәдрәсәдә Коръән уку тәртибен өйрәнү белән бергә, әдәп-әхлак кагыйдәләрен, гакыйдә нигезләрен тирәнтен үзләштергән элекке шәкертләр. Хәзерге көндә мәдрәсәдә укучылар арасында сабыйлар да, яшьләр дә, урта һәм шактый өлкән яшьтәгеләр дә барлыгын әйтеп үтсәк, “бишектән алып ләхеткә кадәр гыйлем ал!” дигән гыйбарәгә тугрылыкның ачык мисалын күрерсез...



Юбилей кичәсе өч сәгать дәвамында барып, сизелмичә дә узып китте. Алма төшәр урын булмаган залда утырган халык та ыгы-зыгыны белми: чыгышларны, мәгънәле сүзләрне, вакыт-вакыт ял иттереп алган көлкеле, әмма мәгънәле сәхнә күренешләрен йотлыгып тыңлап утыра. Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин, Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге мөдире Айдар хәзрәт Карибуллин, республиканың баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, хакимият вәкилләре, башка кунакларның котлау сүзләре; мәдрәсәдә озак еллар эшләгән мөгаллимнәргә мөфтинең Рәхмәт хатлары тапшыру; мәдрәсә мөдире Ришат хәзрәт Курамшинны Татарстан Республикасының Фән һәм мәгариф министры исеменнән “Мәгариф өлкәсендәге казанышлары” өчен күкрәк билгесе белән бүләкләү - бәйрәмнең менә шундый рәсми мизгелләре дә җиңелчә юмор белән сугарылып, залны үзенә “бәйләп” торды да инде. Мәдрәсә шәкертләренең артистлардан һич кимен куймыйча сәхнә күренешләрен тәкъдим итүләре, мөнәҗәтләр башкаруы, чараны алып баручы егетләрнең зәвык һәм җор сүзгә ия булуы да бәйрәмнең күркәм узуына бер сәбәп булды. Сценарий төзегәндә бер генә нәрсә дә күз уңыннан читтә калмаган, карап-тыңлап утырган кешегә сабак, гыйбрәт, файда бирердәй сүз-гамәлләр җентекләп уйланылган.



Юбилей уңаеннан безнең редакция исеменнән котлау сүзләре генә түгел, аерым рәхмәт тә җиткерәсебез килә. “Ислам нуры” газетасын Кукмара халкына ирештерүдә, газетаны эчтәлекле язмалары белән баетып торуда Ришат хәзрәт Курамшинның ярдәме бик зур.

Аллаһы Тәгалә гыйлем бирүчегә дә, гыйлем алучыга да Үзе таяныч булсын; һәркемнең кылган изгелеге үзенә изгелек булып әйләнеп кайтуны насыйп итсен дигән теләктә калабыз.

**Айгөл Әхмәтгалиева.**

## 2019 елда мөселман бәйрәмнәре

**7 март** – Рәгаиб кичәсе

**2 апрель** – Мигъраҗ кичәсе

**19 апрель** – Бәраәт кичәсе

**6 май** – Рамазан ае башлана

**31 май** – Кадер кичәсе

**4 июнь** – Ураза гаете

**10 август** – Гарәфә көне

**11 август** – Корбан гаете

**12, 13, 14 август** – Тәшрикъ көннәре

**9 сентябрь** – Гашурә көне

**8 ноябрь** – Мәүлид-ән-Нәби

## Хаҗга барырга теләсәгез...

Чаллы шәһәрендәге “ДУМ РТ Хаҗ” вәкиллеге хаҗга баручылар өчен дәресләр бирә башлады. Сезне һәр атна саен пәнҗешәмбе көнне кичке сәгать 5 тә “Нур-Ихлас” мәчетендә көтеп калабыз. Дәресләрне “Утыз Имәни” мәчете имамы Инсаф хәзрәт Сәүбанов алып бара.

Белешмәләр өчен телефон: 8 (8552) 56-65-99

## Хөрмәтле дуслар!



2019 елда да “Ислам нуры” газетасы белән бергә калыгыз, безгә хатлар, үзегезне кызыксындырган сораулар юллагыз. Газета “Роспечать” каталогына кертелгән, аңа ел әйләнәсендә язылырга була. Индексы - 54149.

# Намазга җиңел карама!

*Әлхәмдүлилләһи раббил гааләмииин. Вәссаләәтү үәссәләәмү галәә расүүлинә Мүхәммәдиү вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһи әҗмәгиин.*

*Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә әйткән: "Өй әһелеңне – гаиләңне намаз укырга боер, ярлы булсаң да намаз уку, намазга өйрәтү һәм намазга боеру мәшәкатьләренә сабыр ит, Без синнән ризык сорамыйбыз, Без сине Үзебез ризыкландырабыз, эшнең ахырдагы уңышы һәм шатлыгы тәкъва кешеләр өчендер". Ягъни, гаиләңне ризыкландыру турында кайгырмыйча гыйбадәт кыл. Без үзебез ризыкландыручы. Гыйбадәтнең әҗере дә тәкъва мөэминнәргә булачак. ("Таһа" сүрәсе, 132 аять.)*

Раббыбыз Аллаһ "Ниса" сүрәсенең 103 нче аятендә әйтә: "Дөреслектә, намаз вакыты билгеләнгән фарыз гамәл итеп йөкләтелде". Ягъни, намазларны вакытында үтәмәгән кеше Аллаһы Тәгаләнең газабыннан котыла алмаячак. Әгәр дә өстенә йөкләтелгән намазны вакытында үтәп барса, әлбәттә, уңышка ирешәчәк.

"Ий мөэминнәр! Биш вакыт вә җомга намазларына сакчы булыгыз, ягъни намазны көтеп алып, әүвәл вакытында укыгыз, хосусан икенде намазына игътибар бирегез, бер нәрсә дә сәбәп булмасын намазны калдырырга яки кичектерергә, чөнки намазга каза юк, һәм намаз укыганда Аллаһыдан куркып, нык бирелеп укыгыз һәм намазда түбәнчелек белән торыгыз" ("Бәкара" сүрәсе, 238 аять).

Аллаһы Тәгалә ошбу аятьтә намазны вакытында укыгыз, ди. Кайберәүләр, эштә намаз укырга вакытым юк дип, өйләренә кайткач, "казага" калган намазым дип, җыеп укыйлар. Мондый рәвештә казага калдырып укуны Раббыбыз тыйган. Икенчеләре юлга чыгасым бар дип, намазларын вакыты кергәнче укып куярга тырышалар. Әмма вакыты кергәнче намазны уку тыелганына игътибар итмиләр. Шулай ук, намаз укыганда тәкәббер кыяфәттә җиңнәрне сызганып, аякларны аерып, кулларны күкрәккә куеп уку да тыелган.

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһү галәйһи вәсәлләм намаз турында болай ди: "Ассаләвәтү нурул мүэминин. Ассаләвәтү раҗули фи бәйтиһи нурул бәйти". Ягъни: «Намаз – мөэминнең нуры ул. Мөселманның өйдә кылган намазы өен нурландырыр". Икенче бер хәдистә: "Өйләрегезне намаз кылып, Коръән укып нурландырыгыз", – диелә. Ягъни, фарыз намазларны мәчеттә укып, нәфел намазларын өегездә укып, өйләрегезне нурландырыгыз. Елына бер тапкыр азан әйтеп кенә өйләрегез нурланмый, ә намаз укып нурлана.

Ошбу хәдисләрдән аңлашылганча, мөэмин-мөселманның өен нурландыручы намаз булуы ачык итеп әйтелгән. Иман китергәннән соң, кешенең мөселманмы, мөселман түгелме икәнен аерып торучы, ягъни өстенә йөкләтелгән бурычка карата мөнәсәбәтен күрсәтүче булып иң беренче урында намаз тора.

Тагын бер хәдистә: "Кыямәт көнендә кешенең иң беренче хисабы намаздан булачак. Намаз хисабы уңай булган кеше котылыр. Намаз хисаплары уңай чыккан кеше башка хисапларны да җиңел кичәр. Намаз хисабы бозык булган кеше газапларга тап булачак, башка хисаплары да авыр булачак", - диелә.

Өстенә йөкләнгән намазларны вакытында укып баручы мөселман күпкә саваплы булачак, ә инде үзен мөселман дип йөреп тә намаз укымаган, намазларын билгеләнгән вакытта укымаган, намазларына битараф караучы, биш вакыт намазны үтәмәгән мөселманнарга җәза каты булачак. Намазларына җиңел карап, кимчелек белән игътибарсыз укыганнарга һәм намаз укымаган мөселманнарга җәһәннәм газаплары бар. Моңа дәлил итеп Коръән аятьләрендә һәм хәдисләрдә әйтелгән. Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Һәр нәрсәнең бер билгесе була. Иманның билгесе исә – намаз кылу", -диде. Димәк, кешенең иманы ныкмы-юкмы икәнен белү өчен, намаз укыймы-юкмы икәнен белү җитә. Намаз укымаган кеше кяфер белән бер була.

Имансызлыкның дөньяда җәзасы булып кяферлек тора, чөнки ул ышанса, намаз укыр иде, мәчетләргә йөрер иде. Аллаһы Тәгаләгә ихлас күңелдән ышанмаганга күрә, бөтен кешегә дә шикләнеп карый. Ә бит җәзаның иң зурысы, иң дәвамлысы ахирәттә булачак. Моңа дәлил булып ошбу хәдис тора: "Сәбәпсез (гозерсез) вакытында бер намазын укымый калдырган кеше җәһәннәмдә сиксән ел газап чигәр".

Вакытында укылмаган бер намаз өчен сиксән ел газап булгач, гомере буе намаз укымаган кешегә нинди газап буласын күз алдына да китерүе авыр. Әгәр дә кешенең уртача гомер озынлыгы 65 яшь дип алсак: безнең төбәктә балигълык 15 яшьтә җитә диеп саналса, шул гомере буена елга – 1825 намаз, 50 елга – 91250 намаз. Сәбәпсез даими вакытында укылмаган намаз өчен 7 млн. елга кадәр җәзага тартылырга мөмкин икән.

Ислам динендә намаз укуда авырсынырга урын юк. Чөнки авыру кеше намазын үзенең мөмкинчелегенә карап үти. Хәленнән килмәсә, кеше утырып, утырып та укырга хәле булмаса, ятып, ятып та укый алмаса, ишарә белән укырга тиеш булуы әмер ителгән.

Галимнәр әйтүе буенча: "Адәм баласы Аллаһы Тәгаләнең каршына шатланып, мөэмин-мөселман булып барырга теләсә, намазларга азан әйтү белән шул фарыз намазларын даими кылсын. Фарыз намазларны вакытында үтәү – туры юлның билгесе һәм Аллаһы Тәгаләнең канунын үтәү була. Фарыз намазларны мәчеттә – Аллаһы Тәгаләнең йортында үтәмәсәгез, Пәйгамбәребез (с.г.в.) сөннәтен калдыручылардан булырсыз. Әгәр Пәйгамбәребез (с.г.в.) сөннәтен калдырсагыз, азарсыз. Сөннәтне үтәүне һәм фарыз намазларны мәчеттә укуны монафикъ кеше генә ташлар". Сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.) фарыз намазларын даими рәвештә мәчеттә укыган. Без дә, монафикълык билгесеннән котыласыбыз килсә, биш вакыт намазны да мәчеттә укырга тырышырга тиеш булабыз. Хәдистә: "Берәү кырык көн буе бер рәкәгатен дә калдырмыйча, җәмәгать белән мәчеттә биш вакыт намаз укыса, Аллаһы Тәгалә аны тәмугътан һәм монафикълыктан биздерер", – диелә.

Пәйгамбәребез (с.г.в.), намаз укыганда, сәхәбәләрнең тәкбир-тәхримнән башка тәкбирләрдә дә кулларын күтәрүләрен күргәч: "Нәрсә булган сезгә, күрәм сезне, кулларыгызны тыпырчыган ат койрыгы кебек күтәрәсез? Намазда тыныч булыгыз", – дип әйткән.

"Әгәр куенлыктан имин булсагыз, сәфәрдә дә намазларыгызны ашыкмыйча, шартларын җиткереп үтәгез", – ди Аллаһы Тәгалә. Шулай ук намазда кирәкмәгән артык хәрәкәтләр ясамау шарт булып тора. Пәйгамбәребез (с.г.в.) намаз укыганда, намазын укый башлаганда беренче – кереш тәкбирдә генә кулын колак турысына кадәр күтәрә торган булган, ә башка тәкбирләрдә күтәрмәгән. Ә инде тәкбир әйткән саен кул күтәрүчеләр сөннәтне үтәмәүчеләр, ягъни азгыннар була.

Иблис (аңа Аллаһы Тәгаләнең ләгънәте булсын): "Әй Адәм баласы, син минем кебек булуыңны теләсәң, намазны кечкенәгә сана һәм антың чын булса да, ялган булса да ант итүдән чирканма", – дигән. Димәк, шайтанның дусты булу өчен намазга әһәмият бирмичә, кечкенәгә санау җитә икән.

Хәсән Басридән риваять ителде: Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһү галәйһи вәсәлләм әйтте: "Сезгә урлаучының иң яманын әйтимме?" Сәхабәләр әйттеләр: "Әй Рәсүлуллаһ, әйт". Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: "Намаздан урлый торган кешедер". Сәхабәләр: "Намаздан ничек урласын?" - диеп аптырап сорагач, Рәсүлуллаһ (с.г.в.) әйтте: "Рөкүген һәм сәҗдәсен тәмам кылмаса, намаздан урлар".

Хәкәм бине Гуйәйнәдән хәбәр ителә: "Кем дә кем намаз укыганда уңда һәм сулда булган кешеләр турында уйласа, ул кешенең намазы юктыр", – дип. (Ягъни, анда торучы кулын ничек куйган, ничек баскан, нинди хәрәкәтләр ясый һ.б. дип уйласа, намазы кабул булмый).

Ягъкуб Каридән риваять ителә. Ул намаз укыганда, карак килеп, Ягъкубның киемен алып китте. Карак киемне үзенең юлдашлары янына алып баргач, алар Ягъкубның киемен танып: "Ул киемнәрне кайтар. Чөнки без аның догасыннан куркабыз", - диделәр. Карак киемне Ягъкубның иңенә салды, үзенең кылган гамәле өчен гафу итүләрен сорады. Намазын укып бетергәч, Ягъкубка бу хәл турында сөйләделәр. Ул әйтте: "Мин аның киемне өстемнән алуыннан да, кире куюыннан да хәбәрсез булдым, берни сизмәдем".

Рәсүлуллаһ (с.г.в.) әйтте: "Намаз ул – Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешү, фәрештәләрнең сөюе, пәйгамбәрләрнең сөннәте, мәгърифәт нуры, иман тамыры, доганың кабул ителүе, гамәлләрнең кабул ителүе, ризыкта бәрәкәт, бәндәләргә рәхәтлек, дошманнарга каршы корал, шайтанга нәфрәт, иясе белән үлем фәрештәсе арасында шәфәгатьче, кабердә Мөнкир белән Нәкиргә җавап".

Икенче бер хәдистә: "Әгәр мөэмин кеше бер намазны калдырса, укымаса, Аллаһы Тәгалә аның йөзенә: "Бу кеше Минем рәхмәтемнән чыкты, Мин аннан ваз кичтем", – дип язып куяр, әгәр бер кеше бер фарызны калдырса, аның исеме җәһәннәм ишегенә язылып куелыр", диелгән.

Аллаһы Тәгалә Үзе сакласын! Аллаһы Сүбхәнә вә Тәгалә барчабызга да намазларны вакытында җәмәгать белән мәчетләребездә укырга сабырлык -тәкъвалык насыйп әйләсен. Бәрәкәтле маллар, балаларыбызга хәләл күкрәк сөтләре имеп үскән кәләшләр, кияүләр насыйп булсын. Әмин!

**Равил хәзрәт Нуруллин,**
**Чаллының "Туфан" мәчете имам-хатыйбы.**

## Колак салсаң, үкенмәссең

* Бер яхшы эшкә юл күрсәтүче кеше савапта шул эшне эшләүче белән бер булыр
* Кешеләрнең иң хөрмәтлесе - тәкъва булганы
* Яхшы эшләр эшләү кешене яман тәкъдирдән саклый
* Аллаһы Тәгаләгә буйсынмаган кешегә буйсынмыйлар
* Олылар белән утырышыгыз, галимнәрдән кирәкле мәсьәләләрне сорагыз, хикмәт ияләре белән аралашыгыз
* Гыйлемне язу белән беркетегез
* Алган гыйлемен башкаларга өйрәтмәгән кеше - алтын-көмеш җыеп, шуны һичкайда кулланмаган кеше кебек

## СОРАУ-ҖАВАП

*Шәригать белгече **Рәфыйк хәзрәт МИННӘХМӘТОВ** җавап бирә.*

**Сорау:** Хөрмәтле "Ислам нуры" газетасы! Бер соравыма Рәфыйк хәзрәт Миннәхмәтовтан җавап алмассызмы икән? Кайбер имамнар хатын-кызларга женаза намазында катнашырга ярамый, диләр, рөхсәт итмиләр. Бу чыннан да шулаймы?

**Сөмбел ханым, Чаллы шәһәре.**

**Җавап:** - Әгәр женаза намазы йорт ихатасында яки мәчет ихатасында укыла икән, анда хатын-кызның катнашуы рөхсәт ителә. Мәчеттәге җәмәгать намазындагы кебек, иң арткы сафка басарга кирәк. Ә мәнә мәеткә ияреп зиратка бару ярамый, женаза намазы зират буенда укыла икән, хатын-кызлар анда бару дөрес түгел.

Ришат Курамшин

# Соңгы сынау

*(Ахыры. Башы газетаның 22, 23 нче санында)*

...Хастаханә палатасында караңгырак та, салкынчарак та иде. Шуңа микән, әби ерак яшьлектәге теге шомлы, әмма аны бик бәхетле иткән төнне исенә төшерде. “Салкын иде, бик салкын иде шул төн... Тәннәребез калтырады, ләкин бер-беребезне ишетүгә җаннарыбыз җылынды... Чөнки шул җаннарда олы мәхәббәт ялкыны кабынды... Шул вакытта Аллаһы Тәгалә мин бөтенләй белмәгән, гомеремдә бер тапкыр да күрмәгән кешегә күңелемне беркетеп куйды... Гомерлеккә беркетте... И, Нургали... Йөрәгем белән тойдым синең изгелегеңне... чиста күңелле, яхшы кеше булуыңны... Ирләр арасында шундыйлар сирәк була, бик сирәк... Хатын-кызның бәхете ирдән диюләре – хак сүзләр. Тормыш юлдашың ышанычлы, игътибарлы, кайгыртучан булуы, аның күңел җылысын тоеп яшәү чыннан да зур бәхет бит ул. Безне кавыштырган хәтәр-хәвефле шул төндә күңелләребезне җылытып та, яктыртып та җибәргән мәхәббәт хисе Аллаһның рәхмәте белән гомер-бакыйлык булды, кимемәде, сүрелмәде. Нургалиемның күңел җылысын әле дә тоям бит әле мин...”

Хастаханә бүлмәсендәге тынлыкны бүлеп, янәшәдә карават шыгырдаганы ишетелде. Бераздан шул тавышка ыңгырашкан аваз кушылгач, әби: “Бабаем уянды, ни дә булса кирәктер...” – дип борчылып куйды. Шул мәлдә эңгер-меңгерле почмактан әрнүле зәгыйфь тавыш яңгырады:

- Кәүсәрия!..

- Әү, Нургали...

- Бик суык монда... Туңдым мин, Кәүсәрия... Өстәвенә... гәүдәм әллә нишли... сызлый... кысыла...

Машина бәрдерүдән каты имгәнмәсә дә, әбинең аягы сынган була, шуңа күрә ул башта әкрен генә күтәрелеп утыра, аннары зур саклык белән идәнгә төшеп юрганын эләктерә дә, карты яткан каршы якка үрмәләп-шуышып дигәндәй, хәрәкәтләнә башлый. Бабай яткан караватка кадәр килеп җиткәч исә, юрганны аның өстенә яба, һәм кулын учларына алып:

- Монда мин, монда, җаныкаем... Бераз йоклап алдыңмы?

- Аллага шөкер, кадерлем... йокладым... Әллә нинди... төшләр күреп яттым... Хәерлегә булсын...

- Ниләр күрдем, җаныкаем?

- И... сөйләсәң сүз... Яныма ап-актан киенгән... бик матур бер кеше килеп... сөйләште минем белән... Мин аны белмим шикелле... Ә ул: “Без синең белән... инде ике тапкыр... очрашкан идек, ди... Беренчесендә, ди... Аллаһы Тәгалә сиңа... гомер генә түгел... иман юлы ...һәм бик яхшы... пакь күңелле... тормыш юлдашы да... бүләк итте... Икенчесеннән соң... арагызны ныгытып, гаиләгезне ишәйтте... Үзенә тагын да якынайтты... Әйбәт яшәдегез... бу дөньяда, диде... Ә хәзер инде ди... сиңа... кайтырга вакыт җитте...

Соңгы сүзләрне ишетүгә Кәүсәрия әбинең йөрәге дөп-дөп итеп кага башлады. Әмма үзен кулга алып, ул бабайның кулларына бите белән сарылды да, тыныч кына әйтте:

- Төштә аклык-матурлык күрүне хәерлегә юрыйлар... Ә кайтырга дигәне... Без монда әллә дүртенче, әллә бишенче көн түгелме соң? Чыннан да, озакламый моннан чыгарып, кайтарып җибәрерләрдер безне, шәт...

- Кәүсәрия... Миң сиңа бик рәхмәтле... Син мине... бәхетле иттең... Ә ул... дөрес әйтте... бик әйбәт тордык без синең белән... Гаебем булса – кичереп, риза-бәхил бул...

Хәлне аңлап күңеле тулса да, әби бар сабырлыгын туплап, еламаска тырышты.

- Нургали... Иртәгә балалар кайтып җитә, дип хәбәр иттеләр... И, сагынганнардыр инде... Иртәгә, Нургали!..

Бабай беравык дәшмичә ятты. Соңыннан ниндидер бик мөһим нәрсәне исенә төшереп, борчылып, кабаланып иткәндәй, карчыгының кулларын йомшак кына кысып алды да, авыр сулап:

- Кәүсәрия... Мин Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле... Ул мине бәхетле итте... Гомер буе Аның ярдәмен... мәрхәмәтлеген... тоеп яшәдем... Синең белән... булдыра алганча тырыштык... ләкин... шөкер итеп... бетерә алдык микән... Балаларга әйт... барысына... шөкер итеп яшәсеннәр... безне... догадан калдырмасыннар...

Сабыр итеп күз яшьләрен тыеп торса да, әби түзми һәм бабайның күкрәгенә сыенып, тавыш-тынсыз елый башлый. Ярты гасыр элек бер-берсенә ныклап беркетелгән җаннарның озакламый аерылачагын абайлап, ул бу дөньядагы иң якын, иң кадерле кешесе белән хушлашу мизгеле якынайганын аңлый. Моңа ышанасы килмичә, сыңар канаты каерылгандай авырлык тойса да, ул күңеленнән тәкъдир насыйбы белән ризалашты. Шуңа да картына:

- Бер дә борчылма, әтисе... Әлхәмдү лилләһи шөкер – биш вакыт намаз иярләре бит алар, догадан калдырмаслар... – диде.

- Кәү...сәрия... Тагын... шунысын да... әйт... Кәлимәне... телләреннән... төшермәсеннәр...

- Кайсы кәлимәне? – дип сорый әби, каушавыннан саташкандай.

- Ләә иләәһә илләллаһ... Мүхәммәдүр рәсүлүллаһ...

Әби ризалыгын белдерергә дип талпынган арада бүлмә бер мизгелгә яктырып киткәндәй булды... ...һәм ни гаҗәп: күңел халәте тәэсирендә Кәүсәрия абыстай матур чәчкәләр белән тулган зур, иркен болын күрде. Карап туймаслык шул җете, нәфис чәчкәләрнең кәлимәне көйләп торуларыннан болын өсте чыңлап торган тавышка күмелде. Ә чәчкәләр арасында – шатлыклы елмаеп, яшь Нургали басып тора. Бераздан болын әйләнәсендәге киң һәм нык кәүсәле баһадир имәннәр белән яшел яулык япкан ак күлмәкле оялчан каеннар куе яфракларын кыштырдатып, Нургали әйткән кәлимәне кат-кат кабатлый башладылар сыман. Ә бер имән өстендә урта яшьләрдәге Нургали агач ботакларына тотынып, шул кәлимәне елмая-елмая тәкрарлый. Менә ихлас мөэминнәрнең тугры, ышанычлы юлдашы булган шушы кәлимә агач яфракларыннан зәңгәр күктәге ак болытларга күчеп, бар җиһанны тантаналы яңгыратты. Бәхетле болытлар, бөек кәлимәне кабатлый-кабатлый, ерак офыкларга таба юл тотты. Ә алар арасында... йә Раббәл гәәләмиин! – күк гөмбәзен яңгыраткан болытларга кушылып, моңлы мәкаме белән кәлимәне көйли-көйли, ап-пак тукымага төренгән инде өлкән яшьтәге Нургали әкрен генә көнбатышка таба юнәлә... Ә Кәүсәрия... Ул тын да алмыйча өскә карап, талгын гына ерагайган картын моңсулык һәм шатлык илә соклану хисләрен берләштереп чагылдырган нәүмизле дә, өметле дә күз карашы белән озатып, күккә карап тора...

Абыстай өнгә килеп башын күтәргәндә, тынып калган карты инде суламый иде. Колагы белән күкрәгенә янә кысылып, бабайның йөрәк тибешен ишетергә өметләнгән карчык бераздан мәрхүмнән аерыла һәм шушы хәлгә әле ышанып җитмәгәндәй, күпмедер вакыт бер селкенмичә хәрәкәтсез утыра. Болытлар арасыннан кинәт килеп чыккан ай киң тәрәзә аркылы бүлмәне матәм нурлары белән яктыртып алгач кына, Кәүсәрия әби чынбарлыкка кайтып, үзенең гомерлек юлдашы белән уртак булган юлы шушы мизгелдә аерылганын аңлый. Бу вакытта якты ай нурлары хастаханә бүлмәсен генә түгел, Кәүсәриянең олы хәсрәт халәте биләп алган күңелен дә яктыртты сыман, шуңа күрә әүвәл ни эшләргә, ни уйларга белмичә утырган карчык, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп, кулларын догага күтәрә:

- Әлхәмдү лилләәһи Раббиль гәәләмиин! Әссаләәтү үәссәләәмү гәләә расүүлинәә Мүхәммәдин үә гәләә әәлиһи үә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн... Йә Раббым, йә Аллаһ!.. Бакыйлыкка күчкән тормыш иптәшем Габделхак улы Нургалинең рухын шат кыл. Аның кылган гыйбадәтен кабул итеп, гөнаһларын, бәндәчелек белән кылган хата-кимчелекләрен ярлыка, мәңгелек ахирәт тормышында Үзеңнең рәхмәтеңдә булуын насыйп әйлә. Йә Раббым! Үземне дә, балаларым белән оныкларымны да тәүфыйк-һидәять юлында булучылардан кыл! Бу фани дөньядан мәңгелеккә күчкәндә, хәләл җефетем үрнәгендә “Ләә иләәһә илләллаһ Мүхәммәдүр-расүүлүллаһ” кәлимәсен әйтеп, Үз хозурыңа мөэмин-мөселман булып иманлы хәлдә күчүебезне насыйп ит... Йә Раббым! Нургали картым кебек, мин дә Сиңа бик рәхмәтле! Шундый кеше белән кавыштырганың өчен, миңа шундый тормыш юлдашы, шундый балалар, шундый бәхетле гомер биргәнең өчен шөкер хисләремне җиткерәм Сиңа, йә Рабби!.. Йә Илаһым!.. Нургалием белән бүген аерылдык, әмма ышанасым килә: күңелләребез әле очрашачак... Бу дөньяда без бәхетле булдык, ахирәттә дә лаеклы бәндәләрең өчен хәзерләнгән Җәннәт бакчаларында бергә булырбыз дип өметләнәм... Шунда Синең дидарыңны күрү бәхетенә ирешүчеләр арасына эләксәк, бу дөньядагы җиде дистә ярымлык гомергә сузылган сәгадәт Син бар кылган Бәхетнең бер бик кечкенә генә өлеше булганын төшенер идек... Мәңгелектәге бәхет-сәгадәт белән чагыштырганда, безнең бу дөньядагы гомерлек бәхет ул – барлык дәрья-диңгезләр суының бер тамчысы гына кебек... Ләкин дәрья-диңгезләр суы тамчылардан җыелган сыман, ахирәттәге сәгадәт дәрьясы да җир йөзендәге бәхет тамчыларыннан җыела. Шундый һәрбер тамчының асылы – Иман, ягъни Синең барлыгыңа-берлегеңә ышану, йә Раббым! Шушы иман-ышанычтан аерма, мине, зәгыйфь бәндәңне онытма, ялгызымны калдырма, ярдәмеңнән ташлама...

Тәрәз пыяласына шап-шоп итеп бәрелә-сугыла, шыбырдап яңгыр ява башлады. Кемнеңдер, яңгырлы көнне якын кешесен соңгы юлга озатканда, “табигать тә елый” дигәнен исенә төшереп, Кәүсәрия абыстай күңеленнән бу фикергә ризасызлык белдерде. “Нишләп елау булсын, ди! Киресенчә – яңгыр бит ул Аллаһның бик зур рәхмәте, бәрәкәтле нигъмәте! Адәм баласына җир йөзендә яшәргә мөмкинлек бирелүе дә – зур нигъмәт. Әмма яңгыр башланып кайчандыр туктарга тиеш булган кебек, кеше гомере дә кайчан да булса тәмамлана. Иң мөһиме – һәркем Аллаһны танып, гыйбадәт әһеле булып, бу дөньядан лаеклы китәргә тиеш...

Кәүсәрия әби шулай үзалдына уйланып утырган арада хастаханә бүлмәсен кинәт шомлы караңгылык басты. Моңарчы караңгылыктан бер дә курыкмаган карчыкның күңелен ниндидер хәвефле тойгы биләп алды. Күпмедер вакыт шул халәттә утырганнан соң, әллә йокымсырап киткәнгә, әллә аңын җуйганга, абыстай сәер, хәтта гаҗәеп шундый хәлне күзәтә: бүлмәне болытлар арасыннан килеп чыккан ай яктыртып ала һәм аның хафалы яктысында кап-кара киемнән булган килбәтсез, куркыныч бер зат пәйда булып, әби янына килеп баса. Шуны күрүгә абыстай “Әгузү билләәһи минәшшәйтанирраҗим” дип әйтә, шуннан соң теге шыксыз артка чигенә, әмма бөтенләй чыгып китми. Әби “бисмилласын” әйтәм дигәндә генә, кара зат аны бүлдереп, дәшә:

- Нәрсә... харап булдыгызмы?... Харап булдыгыз!.. Халык дөрес сөйли: ул төнне мәчеткә бармаган булсагыз, исән-сау калыр идегез... Ха-ха... Ә Хариска бит ул кичне мин аракы эчерттем... Мин!.. Ә Аллаһ сезне сакламады...

Кәүсәрия абыстай кара затның кем булуын чамалап, бисмилласын әйтеп, болай диде:

- Әлхәмдү лилләһи Раббиль гәәләмиин! Аллаһ Раббыбызның биргәненә шөкер! Безнең белән ни булса да – без бик риза!

- Ю-ук, алай түгел ул... – дип ысылдады кара шәүлә. – Сез бит изге Рамазан аенда, намаздан кайтканда шул бәлагә тарыдыгыз. Шул сәбәпле картың дөнья куйды... Менә сиңа изге ай! Ә бит әле тагын яшәп була иде дөньяда!

- Вәсвәсәләмә, мәлгунь! Картымның изге Рамазан аенда җан бирүе – бик зур дәрәҗә ул! Аннары – кешенең ничек, ни сәбәпле түгел, нинди рухи халәттә китүе мөһим. Тәравихтан кайтканда безне машина бәрдерүе дә – Аллаһы Тәгалә билгеләгән тәкъдир, һәм моңа дәгъва, ризасызлык белдерергә безнең хакыбыз юк! – дип җавап бирде әби, бераз кабаланып.

- Ха-ха! Матур, тыныч картлык кичереп, әле тагын яшәр идегез, дим! Сезнең аерылуыгызга табигать тә елый бүген!

- Аллаһ Раббыбыз биргәненә шөкер! Әле егет чагында бакыйлыкка күчәргә тиеш булган Нургалигә Аллаһы Тәгалә зур бүләк ясады бит: гомер биреп туры юлга бастырды, мөэмин-мөселманнардан кылды. Ә шунда динсез, гыйбадәтсез китеп барган булса? И-и, Аллаһ Раббыма ничек ризасызлык белдереп, ничек оялмыйча елап, бу яңгырны да табигатьнең күз яшьләренә тиңлим?! Юк, без Нургали белән бәхетле һәм бүген вакытлыча гына аерылдык.

- Алай димә... Сезнең әле башкарасы эшләрегез, сөйләшәсе сүзләрегез калды...

Абыстай бермәл уйланып алды: “Чыннан да кадерле хәләл җефетем белән ярты гасыр чамасы бергә яшәдек, ә бер-беребезгә нәрсәдер әйтмичә калдык сыман...”. Ләкин әби шушы вәсвәсәгә дә бирешми һәм ышанычлы, ныклы тавыш белән җавап бирә:

- Юк! Барысы да Аллаһ әмере буенча нәкъ үз вакыты белән башлана һәм тиешле булган вакытта төгәлләнә. Барысы да Аллаһ теләгәнчә...

Шуннан соң абыстай “әгузү-бисмилләә”сен әйтеп, “Аятелкөрси”не укый башлый, аны ишетүгә кара киемле зат юкка чыга. Шул вакытта бүлмә тылсымлы нурлардан яктырып киткәндәй була... ...һәм ни гаҗәп: Кәүсәрия әби алдында шушы төндә инде бер күзәтелгән күркәм манзара ачыла: ул матур чәчкәләр белән тулган зур, иркен болында басып тора, аның әйләнәсендә куе агачларның яфраклары изге зикер сүзләрен кабатлагандай игелекле, талгын җилдә әкрен генә кыштырдый, ә ак болытлы, зәңгәр күктә... йә Раббәл гәәләмиин! – анда... аның сөеклесе... аның кадерле бабае киң итеп елмаеп, аңа кул болгый!.. Сөбхәнәллаһ, мәшәАллаһ! Әйе, Нургали бит бу! Әле китмәгән! Шунда күктә көтеп тора! Иң мөһиме – мине күрә... Әнә бит – миңа кул болгый! Әй, юк... Болгамый... Ул бит кулы белән ишарәләп, үзе янына менәргә чакыра... Әйе-әйе... мен монда минем янга, күккә, дип дәшә бит ул! Менәсе иде, менәсе... Хәзер, җаныкаем, менәм, кадерлем! Менәм!..

Шул вакытта, ниндидер билгесез көчләр тәэсирендә Кәүсәрия әби җирдән аерылып өскә таба күтәрелә башлый. Агач кәүсәләренең очларына җиткәч туктый һәм аска караганнан соң, йөрәге кинәт чәнчеп алудан “аһ” итеп әйтеп куя һәм... астагы күренеш юкка чыгып, бар дөнья ап-акка әйләнә, өстән исә Нургалинең тавышы ишетелә:

- Ләә иләәһә илләллаһ... Мүхәммәдүр рәсүлүллаһ...

Кәлимәне ишетүгә, абыстай шундук аны кабатлый һәм матур тавыш белән шул сүзләрне әйтә-әйтә югарыга – күккә күтәрелә башлый.

- Килеп җиттеңме, җанашым!

- Килеп җитем, бәгырем!

- Мин бик тә шат, кадерлем!

- Шушыдыр ул тәкъдирем!

- Сүбехәнәллаһ!

- Әлхәмдү лилләһ!

- Аллаһү әкбәр!

- Үә лилләһил хәмде!

Һәм бу ике изге җан Аллаһның иксез-чиксез Галәмен бөек кәлимә авазы белән бергәләп яңгыратып, биек күкләргә, йолдызлардан да ераграк булган, Яратучының иман-гыйбадәт әһелләре өчен хәзерләнгән сокландыргыч, хәйран калырлык хозур-ләззәт микатенә таба юнәлделәр...

# Без ничек яшибез?

Яшәү табигый булган кебек, үлем дә табигый. Шуның кебек, авыру да табигый хәл. Бер генә кеше дә авырмый калмый, авыргач, ул сәламәтлегенең кадерен белә. Авыру яшәү рәвеше белән бәйле ул.  Аллаһы Тәгалә Адәмне яраткан. Адәм уң ягына караган да: «Сөбханалла, син кем?» — ди икән. «Мин — сәламәтлек», — дигән чибәр зат. «Син кая керерсең?» — дигәч, «Тәнеңә керермен», — дигән. «Кер», — дигән Адәм. Сул ягына карап, ямьсез заттан: «Әстәгъфирулла, син кем?» — дип сораган. «Мин — авыру», — ди икән тегесе. «Син кая керерсең?» — дигәч, ул да: «Тәнеңә», — дигән. «Син, шушындый куркыныч нәрсә, ничек итеп миңа керерсең?» — дигәч, тегесе: «Мин синең яраткан әйберең аркылы керермен», — дигән. Берәү тозлы, икенчесе баллы әйбер ярата. Кемдер йокларга, кемдер телевизор каршында утырырга ярата. Кыскасы, һәркемнең зарарлы гадәте бар. Яшәү рәвешенә карап, организмда авыру килеп чыга. Авыргач, яшәү рәвешен үзгәртергә кирәк. Ә без яхшы дару, әйбәт табиб эзлибез. Яшәү рәвешен үзгәртү турында уйлап та карамыйбыз.

Берәү табибка килгән. Тулы гәүдәле кеше булгандыр инде, җиләк-җимеш ашап торырга кушканнар моңа. Бу чыгып киткән дә кире кергән. «Сез әйткән ризыкларны ашаганчы ашаргамы, әллә ашаганнан соң гынамы?» — ди икән. Нәрсәдәндер үзеңне тыю, тыелу - безнең өчен сәламәтлек.  Боларның барысына да Ислам дине өйрәтә. Чисталыкка да, хәрәмнән тыелырга да. Намаз укуның да беркемгә дә зыяны тими. Иртәнге намазны вакытында укыган кеше үзенә көн буена җитәрлек энергия ала. Шуңа күрә яшьтән намазга басарга, дингә килергә кирәк.

**Җәлил хәзрәт Фазлыев,**
**Татарстанның баш казые.**

# Мәрхәмәтле булыйк



Ислам дине кеше тормышының барлык якларын да колачлый – безне яхшы гамәлләр кылырга, мәрхәмәтле һәм барлык кешелек өчен үрнәк булырга чакыра. Шушы хөкемнәр җәнлекләр белән мөнәсәбәттә дә чагылыш таба. Динебез безгә аларга карата йомшак, әмма шул ук вакытта гадел булырга, аларның безнең өстебездә булган хакларын үтәргә өнди. Пәйгамбәребездән (с.г.в.) килгән хәдисләрдә җәнлекләрне җәберләү, рәнҗетү җәһәннәм утына, ә инде аларга мәрхәмәтлек күрсәтү җәннәт бакчаларына керү сәбәбе булуы турында әйтелгән. Әлеге темага кагылышлы бер хәдистә болай диелә: “Бер юлчы сусыз кала һәм аның бик нык су эчәсе килә. Тегендә-монда бәргәләнеп, су эзли башлый. Йөри торгач, ташландык бер кое табып ала. Әлеге коега төшә һәм су эчә. Коедан чыгып юлын дәвам итә торгач, юл өстендә шулай ук сусаудан хәлсезләнеп аяктан егылган, телләрен асылындырган, авырлык белән генә сулап яткан бер этне күрә. “Карале, бу эт тә минем кебек сусау хисе белән яна бит”, – дип, әлеге этне бик җәлли. Кое янына кире бара. Тирән генә булган бу коега төшә. Читегенә су тутырып, коедан чыга. Барып, шушы эткә су эчерә. Әлеге гамәле өчен Аллаһ Тәгалә аның бөтен гөнаһларын гафу итә. Һәм җәннәте белән бүләкли”.

Төрле риваятьләрне истә тотып, без шушы кышкы суыклар вакытында шәһәребездә яшәүче җәнлекләргә булышлык күрсәтергә теләп, ирекле эшчәнлек хәрәкәте башлап җибәрергә булдык. Беренче эш итеп “Нур-Ихлас” мәчете янындагы агачка кечкенә җимлек элеп куйдык, һәм ин шаа Аллаһ бу эшне дәвам итәчәкбез. Сез дә безгә кушылырсыз һәм калганнарга да үрнәк күрсәтерсез дип өметләнәбез. Моның өчен җимлек ясап кую һәм аны вакыт-вакыт кошлар ашарлык ризык белән тулыландырып тору да җитә. Шулай ук, бөтен кешеләргә үрнәк буларак, аны фотога төшереп Instagram социаль челтәренә #islamchally хэштегы белән урнаштыра аласыз, чөнки Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бер хәдисендә: “Изге гамәлгә өндәгән кешегә шул гамәлне үтәгән кешенеке шикелле үк савап язылыр”, – диелгән.

Җимлек урнаштырудан тыш, урамда яшәүче мәче һәм этләрне дә игътибарсыз калдырмасак иде. Ашалмыйча калган азыкны чүп чиләгенә ташламыйча, урамдагы йорт хайваннарына бирсәк, ин шаа Аллаһ, яхшы гамәл кылучылардан булырбыз.

Аллаһы Тәгалә ниятләребезне дөресләп, кылган изгелекләребезне кабул итсен.

**Нияз Газизов.**

## Балалар өчен

# Изге иман

*(Гакыйдә)*

***Алып баручы.*** Шәһадәт ул – “Ләә иләәһә илләллаһу үә әшһәду әннә Мүхәммәдән рәсүлүллаһ". “Таныклык бирәм, бер Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаек зат юк, һәм таныклык бирәм, Мөхәммәд –Аллаһының илчесе”, – дип әйтү.

***Бала:***
Беренче терәк – ул шәһадәт,
Бер Аллаһыга ышану кирәк.
Гыйбадәт бер Аллаһыга,
Шик тотмаска бу турыда.
Аның кебек бүтән иләһә юк,
Аллаһыбыз бөек, көчле.
Мөхәммәд (с.г.в.) – Аның илчесе,
Коръән башлап аңа төште.

***А.б.*** Аллаһы Тәгалә “Зәрият” сүрәсенең 56 нчы аятендә: «Мин җеннәрне һәм кешеләрне бары тик Үземә гыйбадәт кылсыннар өчен генә яраттым», – ди. Әгәр дә кеше намазны ихластан укыса, ул аның әхлагын яхшы якка үзгәртә һәм гөнаһлы гамәлләрдән туктата. Намаз кешенең бу дөньяда да һәм ахирәттә дә бәхетле булуының һәм уңышка ирешүенең сәбәбе булып тора.

***Бала:***
Икенче терәк – ул биш намаз,
Аны үтәү – катгый таләп,
Юнәл кыйбла тарафына.
Мактаулар әйт Аллаһыга.
Төнлә, иртән һәм өйләдә
Сәҗдә кыл, син, дустым, Аңа.
Өйләдән соң һәм кичен дә
Тап төшермә намазыңа.

***Бала:***
Өченче терәк – зәкәт булыр.
Уртаклашу байлыгыңнан.



Төгәл сана да акчаңны,
Өлеш чыгар ярлыларга.
Бу дөньяда бирүчеләр
Тик бәхеткә ирешерләр.
Комсыз һәм саран бәндәләр
Югалтулар кичерерләр.

***А.б.*** Байлыгы булган һәр мөселман елына бер тапкыр зәкәт түләргә тиеш (нисабы-күләме шәригать кушканча җитәрлек булса). Аллаһы Тәгалә “Маидә” сүрәсенең 55нче аятендә:”Сезнең дустыгыз бары тик Аллаһтыр, Рәсүлдер, иманлылардыр: алар Аллаһның әмерләренә буйсынучылар, намаз укырлар, зәкәт бирерләр,” – дип хәбәр итә.

***Бала:***
Дүртенче терәк – ул ураза,
Бар кешегә мөһим гамәл.
Һәркем белә: Рамазанда
Аллаһыдан олуг бүләк –
Коръән аятьләре иңгән.
Яңа ай туган чагында
Изге Рамазан башлана.
Таңнан кояш баткангача
Су да йотма һәм ашама.

***А.б.*** Аллаһы Тәгалә Коръәндә “Бәкара”сүрәсенең 185нче аятендә: ”Рамазан ае кешеләргә туры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән индерелә башлаган айдыр. Шуңа күрә шушы айга килеп ирешкәннәр ураза тотсын”, – ди.

***Бала:***
Бишенче терәк – Мәккәгә Хаҗ,
Мөмкинлегең булса әгәр.
Ләкин кирәк тырышырга,
Аллаһыдан бүләк көтәр.
Монда – изге Кәгъбәтулла,
Аны күрү зур сөенеч.
Аллаһу әкбәр дип сәлам бир,
Татлы зәм-зәм суларын эч.

***А.б.*** Мәккәгә хаж кылырга бару – исламның бишенче баганасы. "Кешеләр арасында хажга баруның кирәклеге турында хәбәр тарат”, – ди Аллаһ “Хаҗ”сүрәсенең 27аятендә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) әйткән: ”Кабул булган хажның бүләге – Җәннәт”.

**"Нәниләргә дин нигезләре" китабы буенча китапханәче Сөмбелә Фәхертдинова әзерләде.**

*Фото интернеттан алынды.*

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.
**Тиражы 1280.**
**Индексы 54149**
* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**24 декабрь 16 сәг.**
**фактта 24 декабрь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**